**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 10 ноябре** **№18**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2018 елның 18 октябрендәге 76 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

“Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы” 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законга Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге Советы Уставының 7, 88, 89 ,90 статьялары нигезендә , Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. **12 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, шәһәр округларының генераль планнары (алга таба - иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар) буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар, әлеге статьяның 3_1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла";

**12 статьяга 3.1 пунктчасын өстәргә:**

Җирлекнең генераль планына, шәһәр округының генераль планына үзгәрешләр кертелгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.";

2. Әлеге карарны Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге муниципаль берәмлек башлыгы, Совет рәисе** **Р.Т.Нотфуллин**